## КАРЛЫ КӨЗ
Кыш килде, дип сөенергә иртәрәк әле

> 2

## ТИҢДӘШСЕЗ ҖЫРЧЫ
Зөһрә Сәхәбиеваның шәхес кадере турында уйланулары

> 3

## САБЫРЛЫК СЫНАЛГАНДА
«Ак барс»ка ни булган?

> 4

## ЯЗУЧЫ СҮЗЕ
«Ирнең абруен күтәрергә күп очракта хатынның дәшми калуы да җитә»

> 4


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 168 (28941) | Сишәмбе | 15 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

# НИБАРЫ БЕР АДЫМ...

**Көннәр суытып, җиргә кар ята башлаганчы... Бу көннәрдә авыл халкының да шулай дип тырышуы. Авыл башлыкларының да, күңел тыныч булсын, юллар кардан вакытында чистартылсын дип, эшләрен җайга салып йөргән мәлләре. Авыллар кышка әзерме? Без шул хакта белештек.**

Кайсы гына авылга шалтыратсак та, кышка әзерлекне юлларны кардан чистарту өчен техника хәстәрен күрү белән бәйләделәр. Узган ел Яшел Үзән районының Олы Җәке авыл җирлеге башлыгы Фирая Фәйзуллинаның үзе рульгә утырып, трактор белән кар эттереп йөрүе күпләрне сокландырган иде. Биш авылны карап-җыйнап торган тәвәккәл башлыкның үзе белән сөйләшеп алдык.

– Акча булса, барысы да әзер дигән сүз инде. Иң элек кесәнең калын булуы кирәк шул. Быел анысы Аллаһка шөкер. Кышка запас хәстәрли алдык. Юлларны кардан арындырырга тиешле оешма белән килешү төзедек инде. Без юлларны чистартырга үзара салым акчасын тотмыйбыз, анысының үз урыны бар. Ә юллар өчен өстәмә керем кергән иде. Сезонга бу максатларда якынча 300 мең сум акча кирәк, – диде ул.

Моннан тыш, башлык әйтүенчә, кышка кергәнче юллардагы туннельләрне чүп-чардан чистартып калдыралар:

– Авылда кышкы эшләр аерым бер игътибар сорый инде ул. Су суыртып ала торган җайланманың да катмавын күзәтеп торырга туры килә. Авыл калкулыкта торганлыктан, җил көчле була. Шунлыктан газ сүнеп китү куркынычы бар. Күңелсез хәлләр булмасын дип, көн саен иртән бюджет оешмаларын йөреп чыгам. Шулай да кыш көне иң мөһиме – юллар инде. Аларны көн саен кардан чистартып торырга кирәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Актаныш районының Кәзкәй авыл җирлегендә дә эшләр шушы тәртиптә оештырылган. Камил Әхмәтгалиев әйтүенчә, карны эттерәчәк оешма белән килешүләр төзелгән, эш тәртибе хәл ителгән.

– Алар билгеле бер сәбәпләр аркасында килә алмаса яки көчле буран булса, техникасы булган авылдашларыбызга мөрәҗәгать итәм. Хәлгә кереп, ярдәм итәләр, – диде ул.

Республикадагы күпчелек авыллар, теге яки бу оешма белән килешү төзеп, юлларны алар тәкъдим иткән техника белән чистарта. Шул ук вакытта үз тракторлары булганнар да бар. Әйтик, Азнакай районының Урманай авыл җирлегенә дә берничә ел элек грант нигезендә трактор биргән булганнар. Быел исә үзара салым акчасына яңа кар эттергеч сатып алганнар. Кышын ике авыл юлларын чистартырга шуны җәлеп итмәкчеләр. Моннан тыш, авыл җирлеге башлыгы Эльмира Абдуллина әйтүенчә, оешма һәм тагын бер авылдашларының ярдәменә өметләнәләр.

– Бүген авыл бюджетында юлларны кардан чистарту өчен акча каралмаган. Ләкин шулай булуга карамастан, автомобиль юллары белән идарә итү оешмасы безгә ярдәм итәргә вәгъдә бирде, – диде ул. – Кышын үз тракторында юлларны чистартачак кешегә акчаны үзара салым акчасыннан түләргә исәпләп торабыз. Су юлын ачар өчен дә аерым килешү төзергә кирәк булачак. Бүген әлеге төп эшләр буенча сөйләшүләр тәмамланды. Шуңа күрә авыл кышны каршыларга әзер, дип әйтә алабыз, – диде ул.

Үзара салым акчасы җыю буенча җыеннар уздыру да – алда торган җаваплы эшләрнең берсе. Башкарылган эшләргә нәтиҗә ясап, алда эшлиселәрен барлыйсылары бар.

– Кышка кергәнче авыл янындагы буаның суын киметеп куясыбыз булачак. Алайса язын су басу куркынычы бар. Кышка чүплекләр белән дә кирәсебез килми. Аларны да яхшылап чистартып, тәртипкә китердек. Беренче Май авылында суны каратасыбыз бар иде. Аны башкарып чыгып булмасмы, дип тырышабыз. Кызганыч, бу авылда халык саны да аз, булганнарыннан да үзара салым акчасын җыю авыр. Ә күп эшләр шул хисапка башкарыла. Халык әнә шул җаваплылыкны тоеп яшәсә, аңлашу күпкә җайлырак булыр иде, – диде Эльмира Абдуллина.

Теләчелеләрнең дә бүген кышка әзерләнеп йөргән көннәре. Иске Җөри авыл җирлеге башлыгы Раил Мараков безгә әнә шулай диде.

– Кышка әзерлек бүген дә дәвам итә, – диде ул. – Кар ятып, көннәр суытып җибәргәнче, халык өчен мөһим булган ут, юл һәм суга бәйле мәшәкатьләрне җайга салабыз. Су башнялары даими эшләп торгач, туза. Шуңа күрә алар кышка кергәнче аерым игътибар таләп итә. Юлларны исә техникасы булган, бу эш өчен җаваплы кеше чистарта. Моннан тыш, кышын зират, су юлларын да кардан арындырырга туры килә.

Раил Мараков әйтүенчә, кыш якынлашуы һәр өлкәдә дә сизелә.

– Бездә халык малларны күпләп асрый. Аларны да кышкы сезонга әзерлиләр, җылы сарайларга кертәләр, – диде ул. – Гомумән алганда, авыл халкы быелгы кышны бераз сагаеп көтә. Кәефләре дә дөньядагы вазгыятьнеке шикелле. Барыбыз да, илне сакларга киткән авылдашларыбыз исән-имин әйләнеп кайтсыннар иде, дип телибез.

## Президенттан – дәүләт бүләкләре

Россия Президенты Владимир Путин Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинны Россия дәүләтчелеген ныгытудагы, парламентаризмны үстерүдәге зур өлеше һәм законнар иҗат итүдәге актив эшчәнлеге өчен Александр Невский ордены белән бүләкләү турында указга кул куйган. Әлеге орден дәүләт төзелеше эшендә Ватан алдындагы аерым шәхсән казанышлары өчен Россиянең халыкара абруен ныгытуда, икътисадны, фән, мәгариф, мәдәният, сәнгать, сәламәтлек саклау өлкәләрен үстерүдә күп еллар буе намус белән эшләүче һәм югары нәтиҗәләргә ирешүчеләргә тапшырыла.

Президент Указы белән «Татавтодор» генераль директоры Айрат Шәймиев хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Почет орденына лаек булган.

Моннан тыш, Татарстанда яшәүче Гөлназ Гыйлаҗева, Лилия һәм Мансур Гыйльморатовлар, Айдар Фәретдинов «Ата-ана даны» ордены медаленә лаек булган.

## *Миллиард сумлык сатканнар*

10 сентябрьдән бирле Татарстанда барлыгы ун авыл хуҗалыгы ярминкәсе узган. Фермерлар аларда җәмгысы 1 миллиард 26,2 миллион сумлык азык-төлек саткан. Шәһәр халкы бигрәк тә яшелчәне (13 мең 885,7 тонна) күп сатып алган. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, ярминкәләрдә 9001,9 тонна бәрәңге, 160,4 тонна сөт, 1043,8 тонна ит (635,8 тоннасы – сыер ите) сатып җибәрелгән.

Исегезгә төшерәбез: ярминкәләр һәр шимбә саен Казанның 14 мәйданчыгында, Чаллы һәм Яшел Үзән районнарында – 2, Түбән Камада 3 урында үткәрелә. Моннан тыш, алар төрле вакытта 26 районда уздырылып килә. Республикада көзге ярминкәләр 24 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Аларны үткәрүдә 32 район катнаша.

## Мәчет белән чиркәү янәшә

Түбән Камада мәчет һәм чиркәү төзелешләре өчен тәүге нигез ташлары салынган. Киләчәктә Вахитов проспектында юлның ике ягында ике гыйбадәтханә булачак, дигән сүз. Республиканың дин әһелләре белән киңәшләшкәннән соң, аларны төзергә карар ителгән. Район хакимияте башлыгы Рамил Муллин әйтүенчә, дини корылмалар гына түгел, рухи яктан тернәкләндерү, үстерү үзәкләре дә булачак бу.

Мәчет өчен нигез ташы салуда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Түбән Кама районы имам-мөхтәсибе Салих хәзрәт Ибраһимов катнашкан. Дин йорты Чәбия урамы ягында буш урында төзеләчәк. Аңа «Сәлам» исемен бирү күздә тотыла. Очраклы түгел: Түбән Камага кергәндә, юлчылар иң элек шушы мәчетне күрәчәк.

Изге Спиридон чиркәвенең нигез ташын салуда исә Казан һәм Татарстан митрополиты катнашкан. Чиркәү «Магнит» каршындагы буш урында калкып чыгачак.

Вазгыять

# Ике йөрәккә – бер мәхәббәт

## ТӨБӘКЛӘР АРАСЫНДА КАВЫШУ-АЕРЫЛЫШУ СТАТИСТИКАСЫ

**Рәсми саннарга ышансаң, Татарстанда 2022 елның гыйнвар – сентябрь айларында 19835 никах теркәлгән. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда гаилә коручыларның саны быел 1,3 процентка арткан.**

Бу саннар исә Татарстанга кабат Идел буе федераль округында теркәлгән никахлар саны буенча төбәкләр арасында беренче урынны биләү өчен сәбәп булып тора. Сүз уңаеннан, округта бу елның тугыз аенда 133683 пар өйләнешкән. Былтыргы күрсәткечкә караганда аз гына – 0,6 процентка үсеш тә күзәтелә.

Никахлар саны арту буенча Идел буе федераль округы төбәкләре арасында Киров өлкәсе алдынгы: биредә яңа гаиләләр саны 9,1 процентка ук арткан. Пермь краенда никахлар саны – 4,7, Саратов өлкәсендә – 4,5, Мари Илендә – 3,4, Башкортстанда – 2,4, ә Түбән Новгород өлкәсендә 1,8 процентка арткан. Башка төбәкләрдә исә – Мордовия, Удмуртия, Чувашия Республикаларында, Оренбург, Пенза, Саратов һәм Ульяновск өлкәләрендә теркәлгән никахлар саны кимү юлын сайлаган.

Татарстанда аерылышучылар саны да кими. Быел, әйтик, 5,1 процентка кимрәк андыйлар. Гомумән, Идел буе федераль округында тугыз айда барлыгы 90183 аерылышу теркәлгән. Бу 2021 елның гыйнвар – сентябрь айларындагы күрсәткечләрдән 1,1 процентка кимрәк.

**Никахлар саны буенча төбәкләр исемлеге**

| | |
|---|---|
| Татарстан | 19835 |
| Башкортстан | 18538 |
| Түбән Новгород өлкәсе | 15571 |
| Самара өлкәсе | 15355 |
| Пермь крае | 13300 |
| Саратов өлкәсе | 10453 |
| Оренбург өлкәсе | 8852 |
| Удмуртия | 5917 |
| Ульяновск өлкәсе | 5409 |
| Пенза өлкәсе | 5400 |
| Киров өлкәсе | 5295 |
| Чувашия | 4451 |
| Мордовия | 2838 |
| Мари Иле | 2469 |

**Аерылышучылар саны буенча төбәкләр исемлеге**

| | |
|---|---|
| Башкортстан | 12854 |
| Татарстан | 10786 |
| Самара өлкәсе | 10245 |
| Түбән Новгород өлкәсе | 9646 |
| Пермь крае | 8678 |
| Саратов өлкәсе | 7723 |
| Оренбург өлкәсе | 7276 |
| Удмуртия | 4352 |
| Пенза өлкәсе | 3846 |
| Ульяновск өлкәсе | 3840 |
| Киров өлкәсе | 3831 |
| Чувашия | 3317 |
| Мари Иле | 1978 |
| Мордовия | 1811 |

Сүзгә-сүз

**Илсур ҺАДИУЛЛИН, Татарстанның мәгариф һәм фән министры:**

Мәгариф системасында кәгазь эше һәрвакыт күп булды, әмма укытучының төп бурычы – укыту һәм тәрбияләү. Моны истән чыгарсак, уңай нәтиҗәләр көтү урынсыз. Шуңа күрә без бу юнәлештә бик катгый эш алып барабыз.

**(«Татарстан» журналына әңгәмәдән)**

## РОССИЯДӘ – МАШИНА САТУ

**Октябрь аенда Россиядә 43308 яңа җиңел машина сатылган. «Автостат» агентлыгы мәгълүматларына караганда, бу – узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 63,1 процентка азрак.**

ИҢ КҮП САТЫЛГАН МАШИНА МАРКАЛАРЫ

| | |
|---|---|
| Lada >>>>>>>>>> | 17113 |
| Haval >>>>>>>>> | 4316 |
| Chery >>>>>>>>> | 3838 |
| Kia >>>>>>>>>>>> | 2738 |
| Hyundai >>>>>> | 2720 |

## *Алданганнар*

Өч көн эчендә полициягә мошенниклардан зыян күрүләре турында барлыгы 27 кеше хәбәр иткән. Алар барлыгы 15 миллион сумнан артыграк акчадан мәхрүм калган. Күпчелеге – өлкәннәр. Берәүләр булган бар акчасын күчергән, икенчеләрен исә алдакчылар кредит алырга күндергән.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте хәбәренә караганда, мошенникларның күбесе үзләрен банк хезмәткәрләре дип таныштырган һәм телефонны алган кеше исеменә законсыз рәвештә кредит рәсмиләштерелүен әйткән. Инде хәзер аны каплау өчен тагын бер кредит алырга һәм акчаны мошенниклар әйткән телефон номерларына күчерергә кирәк булган. Мәсәлән, Арчадан 54 яшьлек гимназия укытучысы, кредит алып, ярты миллион сумнан артыграк акчаны аферистлар счетына күчереп куйган.

Тагын 7 кеше, янәсе, акчасын саклап калу өчен, аны «банкның ышанычлы резерв счетына», чынында, мошенниклар кесәсенә күчергән.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

**Дөньяда**

## УРТАК ТЕЛ ТАБУ КЫЕН

Дөнья сәясәтенең агымы кайнар. Дәүләтләрнең үзара җыелып, проблемаларны уртага салып хәл итәргә тырышулары тиешле нәтиҗәне бирми. Көнчыгыш Азия саммитында катнашучы илләр, мәсәлән, АКШ һәм аның партнерларының Украина буенча позициясе аркасында уртак белдерү кабул итә алмадылар. Аңлашыла инде: көнбатышлылар Россияне гаеплиләр һәм Мәскәүгә каршы орбитага башка дәүләтләрне дә тартып кертергә омтылалар. Уртак резолюцияне бертавыштан кабул итәргә кирәк булганлыктан, саммитта тышкы эшләр министры вәкиллегендә Россиянең дә катнашуы моңа мөмкинлек бирми.

Бу атнада Балида G20 саммиты башлана. Анда да шул ук хәл көтелә. Очрашуда Россия вәкилләре булуын да сәбәп итеп, күп кенә лидерлар хәтта уртак фотога төшүдән дә баш тарталар. Эш шуңа барып җитте: Индонезия Президенты Джоко Видодо Көнбатыш илләре лидерларыннан Россиягә каршы риториканы йомшартуларын үтенде. Бу Россиянең уртак резолюция кабул итү белән килешүе өчен кирәк дигән дәлил кулланды.

G20 мәйданында Байден белән Си Цзиньпинның күзгә-күз сөйләшүе көтелә. АКШ лидеры Кытай белән мөнәсәбәтләрне җайларга тели, шул исәптән кытайларның Россиягә каршы санкцияләргә кушылуына да ирешергә чамалый. Әлбәттә, Тайвань проблемасы үзәктә торачак. Белгечләр Тайвань конфликтының коралллы каршылыкка әверелүе дөнья икътисадына ел саен 2,5 триллион долларга төшәчәк, диләр.

Икътисад болай да салмак түнтәрелеш халәтендә. Үткән атнада биткоин яңадан 25 процентка очсызланды. Криптовалюталар – мал саклауның иң ышанычлы чарасы дигән миф юкка чыгып бара. 11 ноябрьдә FTX криптобиржасы банкротлык игълан итте. Компания җитәкчесе Бэнкман-Фрид постын ташлады. Иң яшь ун миллиардер исемлегеннән ул хәзер төшеп калды, чөнки 48 сәгать эчендә байлыгының 94 процентын югалтты. Аның бөлүе – тарихта иң зур банкротлыкларның берсе. FTX түнтәрелешеннән соң күп кенә башка криптобиржаларның күз буу белән шөгыльләнүләре ачыклана башлады. Сәүдәне туктатып торырга мәҗбүр булган биржалар саны арта, чөнки клиентлар криптовалюталардан кача.

Башка өлкәләрдә дә икътисади югалтулар арта. Дөньякүләм корпорацияләрнең чиста табышы июль – сентябрь айларында 3 процентка кимегән. Бу хакта япон белгечләре хәбәр итә. Табыш икенче кварталда 10 процентка кимегән булган инде. Аеруча зур югалтуларны финанс һәм мәгълүмат корпорацияләре кичерә. «Гугл» хуҗасы булган Alphabet, мәсәлән, табышының 27 процентыннан колак каккан. Глобаль финанс тармагының югалтулары 30 процент белән бәяләнә. Реаль секторда да хәлләр әйбәт түгел. Электротехника сәнәгате югалтуы –14, автомобиль төзелешенеке – 11 процент. Лидерлар уртак тел таба алмый үзара ызгышып ятканда, икътисад мәтәлчек ата. Бары тик энергия чыганаклары белән сәүдә итүчеләрнең генә табышлары зур.

**Россиядә**

## ТОМАНЛЫ КИЛӘЧӘК

Үткән атнада Россия икътисадындагы хәлләргә Үзәк банк рәисе Эльвира Нәбиуллина: «Киләчәк хәзер беркайчан да булмаганча томанлы», – дип бәя бирде. Россия гаскәрләренең Херсонны бөек манвер ясап калдырып китүләре сәбәп булдымы шунда бу төшенкелеккә. Андый маневрлар күп булыр әле ул. Дөрес аңларга кирәк: алар махсус хәрби операциянең тизрәк тәгәлләнүе өчен кирәк. Ул тәгәлләнсә, санкцияләр йомшарачак. АКШның финанс министры Дженет Йеллен кайбер санкцияләрнең, сугыш туктаса да, калачагын әйтә, моңа без дә шикләнмибез, әмма барыбер йомшару булачак. Американнар Россия икътисадыннан «базар икътисады» дигән тамганы да алдылар. Бу гамәлнең хәзергә безнең өчен бер куркынычы да юк, әмма стратегик киләчәктә зыян салачак. Ә болай Көнбатышта да Украина белән Россияне сөйләшүләр өстәле янына утыртырга теләүчеләр саны арта. Тик хәзер стратегик инициатива – украиннар кулында, алар шуннан файдаланып, үзләрен тәкәббер тоталар, гаскәрләрне тулысынча чыгаруны таләп итәләр.

Үзәк банк үзенең ел саен игълан итә торган «Основные направления единой государственной денежно-кредитной политики» дигән документын бастырды. Бу – асылда алдагы елга фаразлар. Документта өч үсеш сценарие каралган: беренчесе – база сценарие, икенчесе – позитив сценарий, өченчесе негативтан гына тора, тоташ кризис вәгъдә итә. «Российская газета»: «Пессимистичный сценарий прогноза по развитию экономики Банка России в последнее время стал реальнее, призналась недавно глава ЦБ РФ Эльвира Набиуллина», – дип яза. Эшләрнең кая таба баруын шуннан үзегез аңлагыз инде. Бер нәрсәне искәртәбез: Үзәк банк Россия икътисадын гына түгел, дөнья икътисадының үсешен фаразлый.

Без Россия икътисадына кайтыйк та агымдагы хәлгә күз ташлыйк әле. «Русал» компаниясе генераль директорының персонал буенча урынбасары Наталья Альбрехт элек компаниянең Нигериядәге һәм Гвинеядәге предприятиеләренә белгечләр җибәрү авыр булганын искә ала. Хәзер белгечләр Африкага китеп котылу өчен чират торалар, хәтта командировкага китү өчен медкомиссиягә үзләре түләргә дә ризалар икән. Мобилизация һәм шуңа бәйле рәвештә халыкның чит илләргә агылуы кадрлар дефицитын тудырган. Җиңел сәнәгатьтә – 70, машина төзелешендә – 35, азык-төлек сәнәгатендә 25 процентка кадәр эшчеләр җитешми икән. Җитештерүче бизнесның 48 проценты нәкъ менә шул сәбәпле җитештерүне арттырып булмый, дип зарлана. Компанияләрнең 22 проценты кадрлар «ачлыгы» сәбәпле җитештерүне киметергә мәҗбүр. Технологияләргә һәм финансларга бәйле башка проблемалар да җитәрлек бит әле.

## ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

**Бүгенге катлаулы шартларда хакимият органнарының төп бурычы – халыкны кайгырту. Президент Рөстәм Миңнеханов Татарстан Хөкүмәте йортында узган киңәшмәдә шул хакта сөйләде.**

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләре аерым игътибар таләп итә. «Ил җитәкчелеге, шулай ук республика дәрәҗәсендә хәрби хезмәткәрләрне матди яктан тәэмин итү һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү буенча күп чаралар күрелде, – диде ул. – 7 ноябрьдә без мобилизация буенча Чакырылыш комиссиясенең республика Оператив штабының уртак утырышында бу юнәлештәге эшләрнең һәм бурычларның торышы турында фикер алыштык. Республика Хөкүмәтенә, шәһәр һәм район башлыклары белән берлектә, хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә даими рәвештә ярдәм итү буенча эш алып барырга һәм бу эшкә өстенлек бирергә кирәк».

Рөстәм Миңнеханов искәрткәнчә, хакимияткә балалы гаиләләргә дә ярдәм итү мәсьәләсенә аерым игътибар бирергә кирәк.

* * *

**Рөстәм Миңнеханов Чистайның тарихи үзәген саклау һәм үстерү буенча киңәшмә уздырды. Президент быел май аенда, Чистай тарихи үзәгендә булып, реконструкцияләнергә тиешле мәдәни мирас объектлары белән танышкан иде. Ул вакытта корылмаларны аукционнан сату бурычлары билгеләнде. Кайберләрен дәүләт программалары кысасында тулысынча тергезү планлаштырылды.**

Киңәшмәдә Чистай районы башкарма комитеты җитәкчесе Эдуард Хәсәнов мәдәни мирас объектларында нинди эшләр башкарылуы турында сөйләп үтте. Аларның кайберләре инвесторларда кызыксыну тудырган. Кайбер объектлар буенча конкурс документларын әзерләү эше алып барыла. Эдуард Хәсәнов инвесторларга тергезү эшләрен ике елдан биш елга кадәр җиткерү мөмкинлеген карарга тәкъдим итте. Рөстәм Миңнеханов, реставрацияләү вакытын арттыру өчен, билгеле бер шартларның үтәлергә – корылма фасады һәм түбәсенең беренче өч ел эчендә төзекләндерелергә тиешлеген искәртте.

Чистай башкарма комитеты җитәкчесе 10 тарихи объектның шәһәр өчен мөһим булып танылуын билгеләп үтте. Моннан тыш йортларны сүтүгә мораторий билгеләнгән: бу эш фәкать шәһәр төзелеше комиссиясе белән килештереп кенә хәл ителергә тиеш. Кайбер корылмалар буенча дәүләт тарихи-архитектура экспертизасын үткәрү таләп ителә. Рөстәм Миңнеханов 1 апрельгә кадәр кирәкле барлык документларны әзерләргә, шул исәптән экспертизалар үткәрергә һәм килештерергә кушты.

Киңәшмәдә катнашучылар Чистайда пассажирлар пристанен төзү мәсьәләсен дә карады. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры әйтүенчә, моның өчен кирәкле барлык документлар, шул исәптән экспертиза әзер. Татарстан Президенты, туристларны күбрәк җәлеп итү өчен, Чистайга пристань төзүнең кирәклеген искәртте. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, шәһәрдә туристлык хезмәтләрен үстерү, туристларга шартлар тудыру өчен, эшмәкәрләрне күбрәк җәлеп итәргә кирәк. Аның сүзләренә караганда, Чистай туристларны җәлеп итү ягыннан Алабугадан калышмый. Президент шулай ук глэмпинг (сәяхәтчеләргә чатырлар кору) мөмкинлекләреннән файдалануны тәкъдим итте.

* * *

**Татарстан Президенты, «Россия – Ислам дөньясы» стратегик фаразлау төркеме Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Истанбул үзәгендәге фаҗига сәбәпле, Төркия Президенты Рәҗип Тайип Әрдоганга кайгы уртаклашу телеграммасы юллады.**

«Татарстанда яшәүчеләр исеменнән, шәхсән үз исемемнән Истанбулда бер гаепсез кешеләрнең һәлак булуына бәйле кайгы уртаклашуны кабул итегез. Тугандаш Төркия халкының кайгысын уртаклашабыз, һәлак булганнарның туганнары һәм якыннарына теләктәшлек сүзләре тапшыруны сорыйбыз, бу фаҗигадә зыян күрүчеләрнең һәммәсенә тизрәк савыгуларын телибез», – диелә телеграммада.

## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышы 18 ноябрь көнне (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә. Депутатлар Дәүләт Советы бинасында 18 ноябрьдә 8.00 сәгатьтән башлап теркәлә. Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

### МАРАТ ӘХМӘТОВ – ЯШЬЛӘРГӘ:

# «СЕЗНЕҢ БЕЛӘН ЭШЛИСЕБЕЗ КИЛӘ»

Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгы

**Татарча навигатор, татар юмористлары бәйгесе, танышу-кавышу өчен махсус кушымта, татар телле белгечләр эзләү өчен сайт… Татар яшьләре, телебезне үстерү һәм тагын да популяр итү өчен, төрледән-төрле проектларын тормышка ашырып мәш килә. Хәерфатиха һәм ярдәм сорарга да онытмыйлар, әлбәттә.**

Татар телен саклау һәм үстерүгә йөз тоткан проектлар конкурсының җиңүчеләре турында сүзебез. Дөрес, алда саналган һәм тагын дистәләп проект белән Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе җитәкчесе Марат Әхмәтов яз көне үк танышып, хәерфатихасын биргән иде инде. Бу юлы яшьләр аңа шушы көнгәчә башкарган эшләре турында сөйләде, Марат Әхмәтов, үз чиратында, киңәшләрен бирде. Очрашу «Безнең Татарстан» республика форумы кысасында «Урам» экстрим паркында узды.

Яшьләр тәкъдим иткән 13 проектның да уртак максаты – татар телен, милли мәдәниятебезне саклау, аларга карата мөмкин кадәр күбрәк кешедә кызыксыну уяту. Алар барысы да яшьләргә юнәлдерелгән.

Әйтик, Алмаз Яруллин, шушы максатларга ирешү өчен, «Иске Казан» фестивален уздырырга тәкъдим итә. Дөресрәге, ул командасы белән бу фестивальнең беренчесен уздырган инде, дәвам иттерергә иде, ди. Проект өч этаптан тора – «Һөнәрләр ярминкәсе», «Сабан туе», «Аулак өй». Шул рәвешле яшь буынны милли традицияләребез белән таныштырырга телиләр.

Ә Зөһрә Вилданова белән Райнур Хәсәнов уйлап тапкан «Таптым» кушымтасы татар яшьләренә бер-берсе белән танышырга, аралашырга һәм, бәлки, кавышырга мөмкинлек бирәчәк. Моңа охшаш рус телендәге кушымталар аз түгел, ә бездә берәү дә юк. Күп вакытларын телефонда уздыручы, виртуаль аралашуга өстенлек бирүче татар яшьләренең моңа ихтыяҗы бар, ди авторлар. Хәзерге вакытта кушымтаның техник эшләре тәгәлләнеп килә. Киләсе елның гыйнвар – февралендә файдаланып карарга мөмкин булачак.

Күпләр өчен «Әйдә, шаяРТ» татар лигасы аша таныш булган Рамил Агдеев «Шалт, Мөхәммәтҗан!» проекты турында сөйләде. Стендап жанрында чыгыш ясаучы татар юмористларының үзара ярышуыннан гыйбарәт булган телевизион проект ул. Теләкләре – татар телле аудитория өчен кызыклы, сыйфатлы видеоконтент булдыру.

Билгеле, проектлар бары тик яшьләр өчен генә дип уйланылмаган. Әйтик, навигаторны барыбыз да кулланабыз. Ильяс Гафаров һәм аның командасы менә шушы юл күрсәтүче җайланманы татарча сөйләтергә теләгән. Моның өчен шактый эш эшләнгән инде. «Яндекс» хезмәте белән дә килешкәннәр, төп боерыкларны татарчага тәрҗемә итеп, яздырып та куйганнар. Боерган булса, ел азагына кадәр тәкъдим итәргә телиләр.

Марат Әхмәтов белән очрашуда Айнур Әхмәтов уйлап табып, гамәлгә куйган «Eshlim.tatar» проекты турында да сөйләделәр. Монысы инде – татар телен камил белүче белгечләр эзләү өчен махсус сайт. Шунда ук белгеч буларак та теркәлергә мөмкин. Сайт эшли башлаган, әлегә белгечләр туплыйлар. Инде теге яисә бу белгечне эзләп язучылар да шактый икән. Ихтыяҗ бар һәм зур, ягъни.

Кызганыч, 13 проектның барысы турында да сөйләп бетереп булмас. Һәм барысы да истә калырлык булды, дип әйтү бераз арттыру булыр иде. Марат Әхмәтов та берничәсенә карата сорауларын җиткерде. Гомумән алганда, яшьләр башкарган эш комиссия рәисе тарафыннан хупланды.

– Проектларыгыз, отышлымы алар, отышлыга якын гынамы – барысы да уртак максатка ирешү өчен эшләвебезне күрсәтә, димәк, барысы да мөһим. Кайсындыр аерып әйтә торган түгел. Һәм бу ул дәрәҗәдә мөһим дә түгел. Без аларны хуплыйбыз һәм киләчәктә сезгә ярдәм итәргә вәгъдә бирәбез. Безнең нәкъ менә сезнең белән эшлисебез килә, – диде Марат Әхмәтов, яшьләргә мөрәҗәгать итеп.

Аның фикеренчә, яшьләр өчен проектларны яшьләрнең гамәлгә куюы – икеләтә мөһим.

– Алар бит яшьтәшләренең психологиясен, рухи дөньясын, ихтыяҗларын аңлап эшли. Әйтик, минем ихтыяҗ белән аларның теләкләре туры килмәскә мөмкин. Мин – үз яшемдәге кеше. Ә алар яшьләрнең күңелләренә тирәнрәк үтеп керергә сәләтле. Бу бит гади проектлар гына түгел. Алар яшьләрне татар телен, милли традицияләрне, тарихыбызны белергә, сакларга этәрә. Безнең телебез – кайчандыр үз дәүләте булган көчле халык теле. Аны онытсак һәм онытырга юл куйсак, тарих безне кичермәс, – диде Марат Әхмәтов.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

# ТАБИГАТЬ КӨЙСЕЗЛӘНӘ

**Һава торышы**

**Ноябрь башыннан бирле республикада аномаль җылы һава торышы сакланды. Уртача һава температурасы нормадан 7–8 градуска югарырак иде. Әмма атна ахырына көннәр кисәк кенә суытып куйды. Чиләкләп яңгыр койды, давыл котырды. Күп кенә җирлекләрдә көчле җил түбә калайларын каерды. Давыл вакытында Биектау районының Айбаш авылында хәтта мәчет манарасы җимерелеп төште.**

Татарстан Гидрометеорология үзәгенең һава торышын фаразлау бүлеге җитәкчесе Ирина Трущина һава торышының болай кисәк көйсезләнүен республикада циклон алышыну нәтиҗәсе дип атый. «Моңа кадәр төньяк киңлекләрдә төньяк атлантик циклон хакимлек итте. Алар салкын һавага үтеп керергә ирек бирмәде. Шул рәвешле бездә һава аномаль җылы торды. Хәзер исә Татарстан аша салкын атмосфера фронты уза», – ди белгеч.

Кичә республикада карлы яңгыр яуды. Урыны белән буранлап та алды. Атна башыннан республикада һава температурасы +3…–2 градуска кадәр түбән төште. Синоптиклар бүген дә шундый ук карлы, салкын һава торышы вәгъдә итә. Республикада уртача 2–7 градус салкын булачак. Юлларда – бозлавык, дип кисәтә алар. «12–15 ноябрь аралыгында айлык норманың яртысы күләмендә явым-төшем булырга мөмкин», – ди Трущина.

Синоптиклар фаразлавынча, якын арада көннәр кабат җылытып алачак әле. Казан федераль университеты профессоры, география фәннәре докторы Юрий Переведенцев сүзләренә караганда, кышка кергәндә елның-елында күзәтелә торган гадәти күренеш бу.

– Без кышка керергә әзерләнәбез. Климатик чикләр буенча ул 1 ноябрьдән 21 ноябрьгә кадәр дәвам итә. Күпьеллык күзәтүләр буенча, шушы 19–21 ноябрь аралыгында тәүлеклек уртача температура –5 градустан да түбәнәя, җиргә кар ята. Күреп торабыз: быел октябрь аномаль җылы булды. Явым-төшем дә нормадан ике тапкыр күбрәк яуды. Шуңа күрә бүгенге салкын көннәр – вакытлы күренеш. Якын арада көннәр тагын җылытып алачак әле, – ди Юрий Переведенцев.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Белгечләр ноябрь азагында кар ятачак дип ышандырса да, Балтач районының Яңгул авылында яшәүче «халык синоптигы» Әмир Шәрәфиев башка фикердә. Чын кыш декабрьнең беренче ункөнлегендә генә җитәчәк, дип фаразлый ул.

– Ноябрь аенда көннәрнең болай җилләп-давыллап суытканы юк иде. Кыш килде, дип сөенергә иртәрәк. Быел чын кыш декабрьнең беренче ункөнлегендә җитәр. Ник дигәндә, быел яз да, җәй дә, көз дә ике атнага соңарып килде, – ди Әмир абый.

Быелгы кыш узган елгысыннан салкынрак булачак, дип фаразлый ул.

– Узган ел бездә кыш көне терекөмеш баганалары 30 градуска кадәр дә җитмәгән көннәр күп булды. Быел кыш салкынрак булачак. Әмма аномаль, зәмһәрир салкыннар көтелми. Декабрьдә кыска вакытлы салкын көннәр булса да, кышның беренче ае, нигездә, җылы киләчәк. Чын кышкы суыклар искечә яңа елдан соң башланачак, – дип фаразлый Әмир Шәрәфиев.

Һава торышындагы үзгәрешләргә бәйле кешеләргә бу көннәрдә сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга кирәк. Казан шәһәренең 3 номерлы шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты Гөлия Гыймадиева бу чорда хроник тын юлы, аутоиммун, нерв, йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан, астмадан интеккән, инфаркт, инсульт, коронавирус кичергән кешеләргә, җитлекмичә туган балаларның сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга киңәш итә.

– Һава торышындагы үзгәрешләргә бирешмәс өчен, иң беренче чиратта, иммунитетны ныгытырга кирәк. Туклануга да игътибар итү зарур. Ашаган ризыгыбыз организмга кирәкле витамин һәм микроэлементларга бай булырга тиеш. Авыр эшкәртелә торган, майлы ризыклардан баш тарту хәерле. Ник дигәндә, һава торышы үзгәргәндә, ашказаны эшчәнлеге сүлпәнләнә. Мондый көннәрдә авыр физик эшләрне дә читкә куеп торырга кирәк. Йокыгызны туйдырыгыз. Организмыгыз ял итсен, – ди табиб. – Психологик яктан ял итү дә мөһим. Юк-барга борчылмаска, интернет, телевизордан начар яңалыклар тыңламаска тырышыгыз. Ник дигәндә, һава торышы үзгәрешләренә сизгер кешеләрнең бу чорда кәефләре төшенке була. Хәлне тагын да катлауландырырга кирәкми. Начар гадәтләрдән вакытлыча булса да баш тартып тору, көн буена тиешле күләмдә чиста су эчү, контраст душ керү дә һава температурасы сикерешләрен җиңелрәк уздырырга ярдәм итәчәк. Чамагыз булса, мондый көнне күбрәк саф һавада йөрү яхшырак, билгеле. Саф һава организмны кислородка баета, аппетитны ача. Хәрәкәт тә файдага гына.

**НОЯБРЬ АЕНА ХАЛЫК СЫНАМЫШЛАРЫ**

**17 ноябрьдә** җиңелчә суык икән, кыш суык булмас.
**19 ноябрьдә** кар очса, кыш карлы килер. Әгәр бу көнне җил әсәре дә юк икән, тиздән чын суыклар килеп җитәр.
**20 ноябрьдә** боз катса, димәк, башка җылытмый.
**21 ноябрьдә** җепшек кар яуса, яз айлары яңгырлы булыр.
**24 ноябрьдә** суык, аяз булса, ике-өч көндә һава торышы бозылыр.
**27 ноябрьдә** болытлы яки явым-төшем булса, җәйнең беренче көннәре матур килмәс.
**28 ноябрьдә** яткан кар язга кадәр эреми.
**29 ноябрьдә** юеш кар – буранга.
**30 ноябрьдә** көн кояшлы икән, кыш кояшлы көннәре белән әллә ни сөендермәс.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

## Юмарт көзем

Күзләр җитә, диеп, моңсуланма,
Көзләрдә бит үзгә матурлык.
Күрәсеңме, алтын шәл ябынган
Һәрбер агач – нинди хозурлык!

Шаян җилләр өзеп яфракларны
Келәм итеп түши юлларга.
Ә кәефсез булган чакларында
Илтеп ташлый салкын суларга.

Иртәләрен томан-пәрдә каплый
Ап-ак итеп офык читләрен.
Кояш нуры аны җыеп ала
Сөеп-назлап яр, тау битләрен.

Байлык, муллык бөркеп табигатькә
Алтын көзем аяк басканда,
Бераз гына моңсурак та була
Басу, кырлар бушап калганда.

Көзләр җитә, диеп, моңсуланма,
Көзләрдә бит үзгә матурлык.
Тирә-якка алтын нурын сипкән
Юмарт көзем – нинди хозурлык!

Нина ВАРАКСИНА

# КҮК КҮКРӘП, ЯШЕН ЯШЬНӘДЕ

Моннан җиде ел элек 6 кешедән торган туристлар төркемебез белән Себер якларына барып чыктык.

Собь елгасы бассейнында июнь-июль айлары – тау сыртларындагы карлар эреп, елгада көчле ташулар вакыты. Елганың мул сулы чагында без дә сәяхәтебезгә кузгалдык.

Һәрбер сәяхәттә, гадәттә, хәтергә нык уелып кала торган ниндидер вакыйга була. Бу юлы һәрберебезгә зур сабак бирә торганы яшенле яңгыр яуганда булды.

Ул вакыйга буласы көнне, яңгыр килә башлагач, елга үзәнендә ачыклыкта тукталып, ял итәргә булдык. Чатыр кордык. Һәркем үз эше белән мәшгуль. Сәяхәткә китәр алдыннан бер кешебез хастаханәгә эләкте. Кемнеңдер йогынтылы тәкъдиме белән безнең командада яңа кеше – Геннадий исемле бер кәттә профессиональ фотограф барган иде. Нәкъ «чебен тимәс чер итәр»: бернинди сүз күтәрмәүче, бик нәзберек, назлы, хәзер үпкәләп, көйсезләнеп, черелдәргә әзер торучы, әз генә дә тәнкыйть күтәрмәүче бәндә булып чыкты ул. Мине тик фотограф буларак чакырдылар, рәхмәт әйтегез әле килгәнемә дип әйтте. Исем-әтисенең исеме белән әйтүне таләп итеп, үзен бик тәкәббер һәм эре тотты. Аңа бернинди йомыш йөкләп булмый. Үзе белән фото эшенә кирәкле булган кыйммәтле җиһазларын алган, әйтерсең, кыргый табигать кочагында аңа фотосалон ясап куйганнар. Мин дә мәктәп елларыннан бирле фотография белән шөгыльләнүче булгач, көндәш күреп, үзен һөнәри яктан өстен куеп, гел миңа бәйләнергә сәбәп эзләде.

Аңа елга климаты да, яшәү шартлары да, сәяхәт әдәбе, үзара мөнәсәбәтләр, ашау-эчү бер дә ошамады. Мыж килеп очучы ач бөҗәкләр төркеме дә гел ачуын гына кабартты. Дуслык, бердәмлек, ярдәмләшү төшенчәләре аны әйләнеп узды.

Көтелмәгән хәл буласы көнне күк йөзе гаҗәеп матур иде. Менә әнинең ак тышлы кабарып торган йомшак мендәрен хәтерләткән ак болытлар өере хасил булды. Алар, бер-беренә сыенып, тау-кыяларны, үсемлек-чәчкәләрне, очкан кошларны, әкият геройларын хәтерләтте. Күк күкрәгән, яшен яшьнәгән вакытта болытлар артында күптөрле төстәге нурлар чагылышын һәм сибелешен кызыксынып күзәттек. Бераздан салкынча яңгыр сибәләргә кереште. Көчле җил чыгып, мамык болытларны сорылары белән алыштырды. Яңгыр көчәйгәннән-көчәйде.

Гена яшенле яңгыр астында фотосессия ясарга кереште. Зур һәм бәләкәй штативларын, ара калдырып, җиргә урнаштырды. Яңгыр төшмәсен өчен өсләренә махсус чатырлар куйды. Ә үзе 20–25 метрга читтәрәк, яр кырыенда үсеп утырган ялгыз нарат төбенә басты да фотога төшерүемне сорады.

Арабыздан кемдер аны бу хәтәр урыннан кире кайтырга өндәде. Аңа җавап итеп: «Моңарчы бу нарат агачы 90 ел торган, тагын шул чаклы яшәр әле!» – дип, кулын гына селтәде.

Мин дә, теләр-теләмәс, «Кэнон» фотоаппаратымны көйли башладым. Генага бу ошамады, чөнки аның профессиональ тулы кадрлы «Никон» аппараты минекеннән өч мәртәбәгә кыйммәтрәк йөри иде. «Никон»ның төшерү кнопкасын ача алмый азапландым. Гена, мине булдыксызга санап, орыша-сукрана яныма килеп җитүе булды, кинәт көчле яшен яшьнәп, күк гөрселдәде, теге ялгыз наратны яшен сукты, аңа гөрләп ут кабынды, икегә аерылып җиргә ауды. Бу көтелмәгән хәлдән барыбызга да шок булды. Берни әйтә алмый катып, басып тордык. Геннадий телсез калды, бераздан мине килеп кочаклады да сабыйларча үксеп елады. Ул көнне һәркем үз уена чумды. Хәтта кичке аш вакытында да үзара аралашмадык, төнге йокыбыз да йокы булмады.

Табигатьнең бу куркыныч күренеше – «яшен тәрбиясе» барыбыз өчен дә үтемле булды. Бигрәк тә Геннадий бу вакыйгадан зур сабак алды, үзен ахыргача итагатьле, әдәпле тотты, миңа башка бәйләнмәде, матур гына сөйләште, әйткән сүзләребезгә, киңәшләргә колак салды.

Шәфкать ГАНИЕВ.
Ижау шәһәре

# БУЙ ҖИТМӘС ОЛЫ ШӘХЕС

Аның затлы, күңелнең түренә үтеп керә торган матур аһәңле, ягымлы һәм көчле тавышын куе урман эчендә урнашкан кечкенә генә авылыбызга, безнең өебезгә радио дулкыннары китереп җиткерде.

...Казаннан концерт бирәләр. Мин, әле үсмер кыз, йөгереп барып, радионың тавышын көчәйтәм. Игълан итәләр: «Җырлый Зөләйха Хисмәтуллина. Татар халык җыры «Кызыл төлке». Җыр башлана: «Кызыл да гынай төлке, урман күрке...» Сокланып тыңладым бу җырны, бу тылсымлы тавышны. Әллә нинди серләр бар иде бу җырда. Шул көннән җырчы Зөләйха Хисмәтуллинага да, «Кызыл төлке»гә дә мин гомерлеккә гашыйк идем. Ул вакытта, бу гүзәл тавыш иясе киләчәктә үземнең остазым булыр, дигән уй ялгышып кына да башыма килә алмый иде, әлбәттә.

Операда киң колач белән эшләгән елларында ук, әле бик яшьләй, консерваториядә укыта башларга туры килә аңа. Ректор Нәҗип Җиһанов Зөләйха ханымны бик үгетләп: «Синең укытуың кирәк безгә, яшьләр өчен, халык өчен кирәк», – дип ризалата һәм консерваториядә Зөләйха Хисмәтуллина классы ача. Нәҗип Җиһанов – акыл иясе, алга карап эш итү, алдан күрә белү, тоемлау сәләте бар иде аңарда.

...Зөләйха апа классына беренче мәртәбә дәрескә керүемне һич онытасым юк. Башта мин ишек артында бераз көтеп тордым. Булачак укытучым бер студент кыз белән дәрес алып бара иде. Тыңлыйм: сопрано тавышлы ул кыз төрле-төрле күнегүләр башкара. «Мин бит болай җырлый белмим», – дип уйлап, эчем пошып куйды. Дөресен генә әйткәндә, минем андый тавыш белән җырлыйсым да килми иде...

Зөләйха апа, елмаеп, бик җылы каршы алды. Аналарча кайгыртучанлык белән берничә сорау бирде, яшәү шартларым белән кызыксынды. Мин тулай торакка урнашуым, 15 нче хастаханәнең балалар хирургиясе бүлегендә шәфкать туташы булып эшләвем, ә хәзер инде төнге сменага күчәчәгем турында әйттем. Моны ишеткәч, укытучым җитдиләнеп, бераз уйга калып торды. Аннан соң йомшак кына: «Төнлә эшләп, көндез уку җиңел булмаячак бит. Дәрескә килгәндә тавышыңның яхшылап ял иткән булуы шарт», – диде. Мин кисәк кенә елап җибәрдем. Моңарчы кичергән шик-шөбһәле хисләрем, Зөләйха апа белән беренче очрашуны курку катыш көтүләрем, эштән ике генә сәгатькә сорап китеп, бик дулкынланган хәлдә имтиханда җырлауларым, алырлармы-юкмы дип борчылуларым – барысы да җыелып, күз яшьләре булып тышка бәреп чыктылар. Зөләйха апа, борчылып: «Ник елыйсың?» – дип сорады. Мин шул мәлдә телемә килгән сүзләрне әйтеп салдым: «Мин ул кызлар кебек җырлый алмыйм. Мин сопрано түгел», – дидем. Укытучым көмеш чыңлагандай матур итеп көлеп җибәрде һәм әйтте: «Сиңа алай җырлау кирәкми дә, син үзеңнең тавышың белән, үз моңың белән җырлаячаксың». Һәм, уйларымны укыгандай: «Мин синең тавышыңны үзгәртергә җыенмыйм, тыныч бул. Синең тавышың өчен мин җаваплы», – дип өстәде. Зөләйха апаның шул сүзләреннән соң эчке киеренкелегем кул белән сыпырып алгандай юкка чыкты. Күңелемә тынычлык инде.

Соңрак Зөләйха Хисмәтуллина классына эләгүемнең очраклылык түгел, бәлки Нәҗип Җиһановның теләге һәм ихтыяры белән эшләнүе билгеле булды. Вокал буенча имтиханда Нәҗип Гаязовичның катнашуын, җырлавымны тыңлап, мине укырга алырга карар итүен бәхет эше дими, ни дисең?! «Халыкчан тавыш» ияләренең консерваториягә кабул ителмәвеннән дә бихәбәр идем бит әле мин. Бу кадәресен, кабинетына чакырып, Нәҗип Гаязович үзе аңлатты. «Консерватория тарихында бу беренче тапкыр – без сине эксперимент буларак укырга алабыз. Милли үзенчәлегеңне югалта күрмә, күбрәк татарча, халык җырларын җырларга тырыш. Безгә халыкчан тавышлы профессиональ җырчылар кирәк», – диде ул.

Хәзер, еллар узгач, Зөләйха апага минем тавышым белән эшләү җиңел булмаганлыгын бик яхшы аңлыйм, чөнки халыкчан тавышлар белән эшләү методикасы юк, укыту программалары юк, әлеге өлкә фәнни күзлектән карап өйрәнелмәгән. Тавышымны сулышка кую, үстерү, башкару культурасына өйрәтү, җырлау техникасы һәм башкаруның күптөрле нечкәлекләре мәсьәләләрендә педагогым башка вокалистлар белән ничек эшләсә, минем белән дә шулай ук эшләде.

Ул үзенең һәр укучысын зур сәхнә өчен әзерләде, һәр студентын кабатланмас шәхес итеп күрде. Төрле вакытта төрле сүзләр белән безгә шул фикерне сеңдерде: «Профессиональ җырчы, әгәр тавыш җепселләре җитди зарарланган булмаса, авырганда да җырларга тиеш. Сәхнә кешесе, аеруча юлда, әллә нинди көтелмәгән хәлләргә юлыга. Синең зал тулы халыкка үз проблемаларыңны сиздерергә хакың юк». Җаваплылык дигән төшенчә, әйткәнемчә, аны гомере буе озата килде. Безне дә шуңа өйрәтте. Аның сәхнәдәге эшен күрү без, студентлар өчен, зур мәктәп иде. Шуңа күрә Зөләйха Хисмәтуллина җырлаган бер генә спектакльне дә калдырмыйча тыңларга тырыштык. Бер тапкыр гадәттән тыш хәлнең шаһитлары булырга туры килде. Театрда «Аида» операсының чираттагы куелыш көне килеп җитте. Төп партия – Аиданы – Зөләйха Хисмәтуллина җырлый. Беркайчан да сәламәтлегеннән зарланмаган укытучыбыз шул көнгә каты авырып китте. Аны алыштырыр кеше юк. Аида – бик катлаулы партия. Барыбыз да кайгыга төштек: «Нәрсә булыр?» Театрга «бүген спектакльне күчерерләр» дигән уйлар белән бардык. Һәм... чын могҗиза булды! Зөләйха апа героик партияне шулкадәр яхшы итеп җырлап чыкты, Аида образын тетрәндергеч дәрәҗәдә гәүдәләндерде ки, аның авыру тавыш белән җырлаганын тамашачы сизмәде дә. Үзе искиткеч чибәр һәм сөйкемле! Халык артистканы аяк өсте алкышлады, чәчәкләргә күмде, күпләрнең күзләрендә яшь иде.

Тагын бер факт. Опера театрында мәшһүр Дмитрий Шостаковичның (шул вакытта СССР Композиторлар берлеге рәисе) «Катерина Измайлова» операсы барган көннәрдә автор, Катерина Измайлова партиясен Зөләйха Хисмәтуллина башкаруында тыңлар өчен, Казанга махсус килә торган була.

Ир хатыны, өч бала тәрбияләп үстергән ана буларак, укытучыбыз тормыш итү, дөнья көтү мәсьәләләрендә дә безне сиздерми генә үз үрнәгендә тәрбияләде, «гаилә – кеше тормышының иң мөһим өлеше, иң зур бәхет, ныклы тыл» дигән фикерне кальбебезгә сеңдерде. Югары әхлак иясе булган Зөләйха апа дөньядан вакытсыз киткән ирен – талантлы музыкант Рәшит Таймасовны яратып, сагынып яшәде. Рәшит абыйның тормышта терәк, гаиләсен, балаларын кайгыртучы ата, хатынын аңлый һәм зурлый белүче чын ир кеше булуы турында сөйли, үзенең сагышларын безнең белән, укучылары белән дә уртаклаша иде. Без, авыл балалары, аңа Зөләйха апа дип эндәшәбез, һәм бу аңа ошый иде. Минем үземә аның җитәкчелегендә педагог хезмәтен башлап җибәрү насыйп булды.

Зөләйха апа безнең гаиләгә дә бик ярдәм итте. Студент елларыбызда, тулай торакта яшәгән вакытта, ирем Хәйдәр Бигичев каты авырып киткәч, ул үз өендә аның өчен үлән ванналарына кадәр әзерләде... Беренче баламны тапкач, бала тудыру йортыннан алырга Хәйдәр белән Зөләйха апа да килде. Бәбәй кайту хөрмәтенә ул патшалар өстәле әзерләп куйган иде...

...Зөләйха Хисмәтуллинаның шәхесен төгәл итеп ачып бирерлек сүзләр эзлим. Казанның Бишбалта бистәсендә үскән, җырчы булу хыялы артыннан, укырга дип, Ленинградка чыгып киткән, сугыш башлангач, кайтып, укуын туган шәһәрендә дәвам иттергән, югары белем алып, опера сәхнәсенә күтәрелгән үзе тыйнак, үзе кыю кыз... Без белгән Зөләйха Хисмәтуллина инде ТАССРның, РСФСРның халык артисты. Аның образы минем күңелемдә, хәтеремдә ачык саклана, ә шулай да асылына лаеклы сүзләр таба алмыйм шикелле. Буй җитмәс олы шәхес, тиңдәшсез җырчы, бәяләп бетергесез остаз һәм тәрбияче, мәрхәмәтле Ана иде ул... Мин остазым Зөләйха Гатаулла кызы Хисмәтуллинаны бетмәс-төкәнмәс рәхмәтләр белән искә алам һәм рухы шәрифләренә догаларымны юллыйм. Ходай кабул итсә иде.

Зөһрә СӘХӘБИЕВА,
Татарстан Республикасының халык артисты

## Үзен бәхетле саный

Мамадыш районы Югары Кыерлы авылында яшәүче ветеран укытучыбыз Мәрзия апа Нурмыева унынчы дистә белән бара. Тормышта үзенең йөзләрчә укучыларына гына түгел, барлык авылдашларына, таныш-белешләренә үрнәк ул. Илле елдан артык элеккеге «Социалистик Татарстан», бүгенге «Ватаным Татарстан»ны укып, ил-көн яңалыклары белән танышып бара. «Редакциядә эшләүче журналистлар минем өчен үз гаиләм сыман», – ди.

Без мәктәп елларыннан ук аның катлаулы тормыш юлы белән якыннан таныш. Әтисе Хөснетдин агага кулак ярлыгы тагып, гаиләне әллә кайдагы Амур өлкәсенә сөрәләр. Мәрзия апа шунда туа. Әнисе Галия апаның, абыйлары Ибраһим һәм Габделәхәтнең сөргендә ничек итеп авырлыклар кичерүен сөйләгәндә, без елый-елый тыңлый идек. Өченче туганы – Хөршит апасын тирә-күрше, туган-тумача, сөргенгә җибәрмичә, яшереп алып кала.

Туганда ук кайгы-хәсрәткә уралган балага сабый чактан ук күп төрле сынаулар аша узарга туры килә. Әтиләре шахтада эшләсә дә, сөргендә яшәү бик авыр була. Ике абыйсы каты авырудан соң бер-бер артлы дөньядан китеп бара.

Бер тәрәзәле баракның салкын идәннәре әти-әнисенең дә, кечкенә кызчыкның да сәламәтлеген какшаткан. «Җиде яшем тулгач, әни мине: «Бар, караңгы, салкын өйдә бер үзең утырма. Анда җылырак булыр», – дип, мәктәпкә илтеп куйды. Балалар арасында иң кечкенә гәүдәлесе идем. Шуңадыр, беренче партага утырттылар. Мәктәп еллары хәтеремдә иң якты истәлек булып калды, – дип искә ала Мәрзия апа. – Башлангычны тәмамлагач, олы юлдан барганда 40 чакрым ераклыктагы бер авылга йөреп укыдык. Турыдан китсәң, юл кыскарак дип, сазлык, баткаклык аша бара идек. Кыш көннәрендә, чиратлап, кар өстендә юл яра идек».

Мәрзия апаның сөйләгәннәрен тыңлап, без, аның укучылары, үзебезне бәхетлерәк тоя идек. Ул булганның кадерен белеп яшәргә өйрәтте.

Укытучыбыз сөйләвенчә, гаепсез булулары расланып, гаиләгә туган якка кайтырга рөхсәт бары тик 1947 елда гына бирелә. Бу вакыта инде әтиләре шахтада эшләп, нык бетерешкән, туктаусыз авырый торган була. Юлда хәле катлаулангач, Новосибирск шәһәрендә поездда төшәргә туры килә. Шулай итеп авылда иң уңган, иң булган кешеләрнең берсе, үзенең хәләл хезмәте белән җир эшкәртеп, терлек асрап көн күргән Хөснетдин аганың ерак Себер якларыннан туган ягына ашкынып кайтканда гомере өзелә.

«Безгә кайтырга ерак иде әле. Ул арада әйберләребез юкка чыкты. Билет алырга акча юк. Дүрт көн вокзал идәнендә аунаганнан соң, әтинең үлүе турында документны күрсәткәч, көч-хәл белән поездга утырдык. Туган якта да көтеп торучы юк. Торыр урын, эшләргә эш табу да җиңел булмады», – дип сөйли Мәрзия апа.

Укытучыбыз шул вакытларда үзләренә ярдәм иткән кешеләрне гел рәхмәт сүзләре белән искә ала. Авырлыкларны күп күрсә дә, үзен бәхетле саный ул.

Рәмзия ГАБДРАХМАНОВА

## КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы коллективы, танылган педагог, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе корреспонденты, техник фәннәр докторы, профессор, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган фән һәм техника эшлеклесе, КНИТУ-КАИның гомуми физика кафедрасы профессоры

**Гали ЮНЫС**

вафат булу сәбәпле, туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Гали Юныс Татарстанның мәгариф һәм фән өлкәсен үстерүгә зур өлеш кертте, үзен аямыйча хезмәт итте.
Олы йөрәкле остазыбызның рухы тыныч, туфрагы җиңел булсын. Сезгә сабырлык һәм түземлек телим.
Олпат шәхеснең якты истәлеге безнең йөрәкләрдә озак еллар сакланыр.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

Язучы фикере



Марат КӘБИРОВ

# Гаилә башлыгы

**«Мин – гаилә башлыгы! – дип мактанырга ярата инде ул. – Гаилә башлыгы мин. Һәм вәссәлам!» Хатыны дәшми. Беренчедән, ире таза гәүдәле дастуин кеше – йодрыклары зур, имән өстәл дә дер селкенеп ала. Икенчедән, ир белән бәхәскә тел әрәм итү бик үк дөрес түгел кебек тоела. Талаш-гауга юк кына нәрсәдән чыгып китә бит инде ул, сугышка да әйләнергә мөмкин, фаҗига дә китереп чыгаруы бар. Ә болай… дәшми калсаң… күпкә уңайлырак…**

«Менә хатын-кызның аның кулыннан нәрсә килә? – дип фәлсәфә сата ире. – Ярый инде, бала таба беләләр, анысы да әле ирләрдән башка түгел. Ә хуҗалыкта… Чүкеч-балта тотамы алар, җир эшен беләме? Хәтта әзер әйбер дә сайлый алмыйлар бит… Менә мин үзем! Быел, әйтик, бәрәңгенең шундый сортын сайлап алып кайттым: колорадо коңгызы якын да килеп карамады. Ә күршеләр өч тапкыр агу сипте, шул килеш тә бәрәңге сабаклары корып бетте. Менә шулай ул…»

Янында дус-ишләре булса, моның авызына гына карап торалар. Баш кагып ризалашалар, сүзен җөпләп, үз тормышларыннан мисал китергән булалар. Эчтән генә көнләшүчеләре дә бардыр инде, чөнки шул дәрәҗәдә гаилә башлыгы булу һәркемнең дә кулыннан килми бит. Бер эштә баш булсаң, башкасында түш буласың. Ә бу бөтен өлкәдә дә – гаилә башлыгы…

«Әле менә курортка барып кайттык. Хатын Бәкергә дигән иде, мин Төркияне сайладым. Ой, ял итеп тә карадык, малай! Ай, андагы матурлыклар…»

Юк, көнләшми дә булмый бит. Ир шулай кукрәген киереп, силсәвит персидәтеленеке кебек көр тавыш белән дөнья яңгыратып сөйләнеп утыра. Ә хатыны күзләрен аска төбәп кенә табынга ризык куя. Ник бер каршы төшсен дә ник берәр караңгы чырай күрсәтсен! Менә шулай булгач, чынлап та гаилә башлыгы булып чыга бит инде. Үзен куя белгән, димәк. Ә бу бик ансат нәрсә түгел. Бөтен яклап та әйбәт булмасаң, хатыныңның хаҗәтләрен, гаилә ихтыяҗларын тиешенчә канәгатьләндермәсәң, бу дәрәҗәдә иркен тоталмыйсың үзеңне. Хатын-кыз бит ул бернәрсәне дә аяп тора белми, күзе үткен, теле чага торган. Бер генә сыйфатың камил булмаса да, ул ярты сүз, хәтта күз карашы яки йөз чалымы белән шундук урыныңа утыртып куя. Хәтта бар яклап диярлек камил булсаң да, бу дәрәҗәдә мактанып утыра алмыйсың, барыбер берәр кимчелегем бардыр, ул тиклем үк кыланмыйм әле, дип уйлыйсың. Ә бу… Үз-үзенә тулы ышаныч белән сөйләшә. Сүзләре мактану кебек тә яңгырамый аның. Хәтта горурлану шикелле дә түгел. Бу чынбарлыкны сөйләү кебек кенә…

Чөнки янында хатыны бар. Ул янында булмаганда теләсә ничек мактана аласың. Хет нәрсә сөйлә! «О, мин аны кол урынына йөртәм, ике аягыннан тотып, өй идәнен дә аның чәче белән генә себерәм. Нинди гүзәлгә күзем төшсә, шуны өйгә алып кайтам, ул табын әзерләп, урын җәеп көтеп тора. Чөнки мин – гаилә башлыгы…» Хатының үзе булмаганда шулайрак та кылтаерга мөмкин. Ә моныкы үз янында йөри. Авыз ачып, бер каршы сүз әйтми, канәгатьсезлек белдерми. Шулай булгач, ирнең һәр сүзе – чынбарлык, һәр кыланышы үрнәк булып тоела.

Кунак-фәлән җыелса, моның буасы китә инде. Ресторанда официант чакырган шикелле, бармак шартлатып кына утыра: «Хатын, теге ризыкны китер әле, монысын чыгар әле… Хатын!» Хатыны берни дә дәшми, ул ни кушса, шуны эшләп тора.

Яхшы бит инде, бер карасаң. Тик бу хәл кунакка килгән ирләрнең дә, хатыннарның да ачуын чыгара. Канәгатьсезлеген уята, дияргә кирәктер инде, ачулану ул тирәндәрәк була бит, ә канәгатьсезлек шундук йөзгә чыга. Ир-атлар аның янында үзләрен, бик мескен үк булмаса да, ярыйсы гына кимсетелгән зат итеп тоя, чөнки берсенең дә бу дәрәҗәдә гаилә башлыгы була алганы юк. Шуңа күрә йорт хуҗасы гаилә башлыгы гына түгел, ә дөнья башлыгы булып тоела. Аның янында бөтен ир-ат мескен кебек кала. Сокланырга кирәк инде шундый ир-егеткә. Тик сокланып булмый, соклану өчен я зуррак, я тиң булырга кирәк. Мескеннәр үзләреннән зурракларга соклана алмый, мескенлек ул һәрвакыт көнләшү хисе уята.

Шундый хәлләр менә. Бу гаилә белән бик яхшы таныш һәм күп нәрсәләрдән хәбәрдар булгач, мин генә мыек астыннан елмаеп утырам. Ничек аңлатыйм инде аны сезгә? Менә бәрәңге… Аның шундый сорты барлыгы турындагы язманы бу ирнең телефонына мин җибәрдем. Хатынының үтенече буенча. Төркия курортлары турында язылган журналны хатын иренең өстәлендә үзе онытып калдырган… Һәм һәр эштә диярлек шулай.

Кызыксынучан кеше буларак, минем сораганым да бар:

– Бер дә хәтереңне калдырмыймыни соң?

– Юк, – дип елмая ханым. – Әйбәт кеше бит ул. Гаилә өчен яши торган зат, мине дә, балаларны да ярата. Ә бу кимчелеге… Ташка үлчим генә бит ул…

Мин уйга калам. Ирнең кимчелекләрен хатыны әһәмиятсез дип саный икән, алар чынлап та әһәмиятсезгә әйләнә. Алай гына да түгел бугай әле… Ирнең абруен күтәрү өчен күп очракта хатынының дәшми калуы җитә. Ә тагы да гадирәк итеп әйткәндә, болай булып чыга… Хатының сине гаилә башлыгы дип уйлый икән, син чынлап та… Юк! Хатының сиңа: «Мин – гаилә башлыгы», – дип уйларга мөмкинлек бирә икән, син чынлап та гаилә башлыгы була аласың…

Ә сүз барыбер матур яңгырый: «Мин – гаилә башлыгы!»

Спорт

# ҖИТМИ САБЫРЛЫК

**«Ак барс» тамашачысына ноябрь дә сөенеч алып килмәде. Октябрьдә 12 очрашуда 9 мәртәбә оттырган Казан командасы көзнең соңгы аена кергәч, 6 уенда нибары 2 тапкыр җиңү яулый алды. Соңгы өч очрашуның барысы да уңышсызлык белән тәмамланды. Олег Знарок нәрсә эшләргә җыена?**



ak-bars.ru

Түбән Камада «Нефтехимик»ка җиңелеп, Түбән Новгородта «профессор» Игорь Ларионов җитәкчелегендәге яшьләр тарафыннан тар-мар ителгәч, «Ак барс» үз бозында «Авангард» белән очрашты. Узган ел плэй-оффның беренче өлешендә үк Казан командасын ярыштан төшереп калдырган Омск уенчыларына каршы узасы матч якташларыбыз өчен зур сынау булырга тиеш иде. Җитмәсә, чагыштырырлык яклары да бар. Көндәшләр дә быелгы сезонны уңышсыз башлады. Әмма «Авангард»та хәлиткеч адымга барып, моннан бер ай элек баш тренерны алмаштырдылар. Яңа сезонга рәттән 6 очрашуда оттыру белән килеп кергән команда, Михаил Кравец килгәч, ноябрьдә 7 уенда җиңү яулады. Уен башында ук ике алка керттергән «Ак барс» икенче периодта көндәшенә башын күтәрергә дә ирек бирмәде. Әмма өченчесендә янә «Авангард» алга чыкты һәм Казаннан җиңү алып кайтып китте.

Казан командасы соңгы 19 матчта төп вакытта бары бер мәртәбә генә җиңү яулый алды. 30 октябрьдә Казан командасы үз бозында 5:2 исәбе белән «Нефтехимик»ны откан иде. «Кара октябрь» шуның белән тәмамлангандыр дип уйлыйм», – дигән иде ул очрашудан соң «Ак барс» һөҗүмчесе Артем Лукоянов. Юк икән шул, көзнең соңгы ае да тамашачыга сөенеч алып килмәде.

Мәгълүм спорт басмаларының берсе КХЛда чыгыш ясаучы команда остазларының рейтингын төзегән. Михаил Кравец – икенче урында. «Ак барс»ның баш тренеры Олег Знарок исә – арттан икенче урында. Рейтингны төзегәндә клубларында остазларга карата ышаныч дәрәҗәсе, нәтиҗә, ягъни очколар һәм алкалар, уен сыйфаты һәм җәмәгатьчелек фикере исәпкә алынган. Олег Знарокта бу өстенлекләрнең берсе генә бар. Анысы – шартлы рәвештә. Командасы бер уен артыннан икенчесен оттырганда Казан клубының генераль менеджеры Марат Вәлиуллин баш тренерны эшеннән җибәрү турында уйлап та карамаганнарын берничә мәртәбә кабатлады. Бу – күптәнге традиция. Татарстан спортында сезон барышында остазларны алмаштыру – бик сирәк күренеш. Андый карарны җиде түгел, хәтта җитмеш мәртәбә үлчәгәч кенә кабул итәләр. Бигрәк тә «Ак барс» кебек клубта. Димәк, сабырлык кирәк булачак әле.

Ә менә нәтиҗәләр, уен сыйфаты һәм җәмәгатьчелек фикере Олег Знарок файдасына түгел. «Ак барс» уенын карагач, баш тренер үзенең «йолдыз»лары белән ни эшләргә белми аптырый дигән фикер кала. Составның үзгәрүе – бер хәл, соңгы очрашуларда хәтта аерым мөнәсәбәт күрсәтелергә тиешле капкачыларның алмашынып торуы да команда эчендә тотрыксызлык хөкем сөрүен раслый. Олег Знарок хоккей дөньясында уенчыларны рухландыра, бер йодрык итеп туплый белгән остаз буларак билгеле. Тактика өчен исә аның белән бергә эшләгән ярдәмчесе Харийс Витолиньш җавап тотты. Хәзер Витолиньш юк. Уңыш өчен кирәкле төп шартларның берсе булмагач, икенчесе дә килеп чыкмый. «Хаталар турында миннән сорамагыз. Аларны мин ясамыйм бит», – диде Знарок «Авангард»ка каршы очрашудан соң. Бу сүзләр баш тренер белән уенчылар арасында элемтә юклыгын дәлилли түгелме? Алай икән, команда эчендә тарткалаш, хоккейчыларның төркемнәргә бүленеп, үзара ызгышып ятулары турындагы сүзләр тренерның уңышсызлыгын аклау өчен махсус таратылган булуын фаразларга җөрьәт итәргә була. Моңа кадәр иң яхшылар сафында йөргән уенчылар бер җәй эчендә генә кәшәкә тота, алкага суга алмый, юктан кагыйдә боза башлый икән, сәбәбен башка җирдән эзләргә кирәк.

Спортчылар күбрәк алка кертеп, очко туплау һәм чемпион исеме өчен генә түгел, алар тамашачының кәефен күтәрү өчен дә чыгыш ясый. Бүгенге шартларда бигрәк тә. «Ә боларның гаилә бозудан башка эшләре юк», – ди хәтта спорттан ерак кешеләр дә. Бераз гына арттыру, әмма хакыйкатьтән дә ерак түгел. Киләсе очрашуда «Ак барс» үз бозында СКА – бу сезонда иң күп очко туплаган команда белән очраша. Әлеге матчның Казан тамашачысына сөенеч алып килүе бик шикле. Бу сүзләр ялгыш булсын иде дә бит…

Илнар ХӨСНУЛЛИН

**КӨНЧЫГЫШ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ**

| | команда | уен | очко |
|---|---|---|---|
| 1 | Автомобилист | 29 | 40 |
| 2 | С. Юлаев | 29 | 40 |
| 3 | Металлург | 29 | 39 |
| 4 | Адмирал | 30 | 38 |
| 5 | Сибирь | 31 | 37 |
| 6 | Авангард | 30 | 35 |
| 7 | Ак барс | 29 | 29 |
| 8 | Барыс | 30 | 28 |
| 9 | Трактор | 30 | 27 |
| 10 | Амур | 27 | 24 |
| 11 | Нефтехимик | 29 | 23 |

Сораштыру

## «Ак барс»ның уенын ничек бәялисез?

**«Сез җиңәсез – без дә сезнең белән җиңәбез, җиңеләсез икән, без дә җиңеләбез». Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Ак барс» уенчылары белән очрашканда шул сүзләрне еш әйтә. Билгеле, җанатар кайчан да командасы өчен җан атачак инде ул. Җиңелгәндә бер дә рәхәт түгел анысы. Җанатарлар җиңү төмен оныта да бара түгелме соң инде? «Ак барс»ның быелгы сезонына нинди бәя бирә алар?**

**Нияз Рахман (алып баручы):**

– Быелгы сезонны зур түземсезлек белән көткән идек. Бер командага моның кадәр «йолдыз»ларны җыюның яхшы һәм начар яклары хакында белгечләр алдан ук кисәттеләр. Төп бәлабез бүген психологиягә бәйле. Тренерлар белән уенчылар төрле дулкында кебек. Олег Знарокның ярдәмчеләренә шулай ук сораулар шактый. Сакчылар начар уйный, гел хата ясыйлар. Нишләп соң? Җавап юк. Бәлки, башкаларны алып карарга, үзгәрешләр кертергәдер? Шул ук Кирилл Адамчук, Кристиан Хенкель, Дмитрий Юдин «Ак барс» дәрәҗәсендәге уенчылармы соң? Кызганыч, уеннарны карау ләззәткә түгел, ә газапка әйләнә. Күңел кайта. Ә бит «Ак барс»ның болай җиңелүләргә күптән «батканы» юк иде. Олег Знарок, ничек кенә акланулар эзләмәсен, ахыргы нәтиҗә өчен барыбер баш тренер җаваплы кала инде. Әлбәттә, өмет бар әле. Ләкин уеннан уенга сабырлык та кими бара.

**Гөлфизә Камалиева, «Ак барс»ның иң өлкән җанатарларының берсе:**

– Миңа хәзер – 67 яшь. «Ак барс»ның читтәге уеннарына да барам. Менә Уфада, Түбән Новгородта булдым. Казандагы матчлар турында әйтеп тә тормыйм. Җанатарлар секторында барысы да яхшы. Без командабызга ышанабыз! Кем әйтмешли, кайгыда да, шатлыкта да бергә. Минемчә, командабыз инфекция йоктырган. Сихәтләнмичә, нәтиҗә булмаячак. Күмәк иммунитет кирәк! Яңа җиргә эшкә урнашкач та бит үзеңне ничек тотарга белмисең. «Ак барс»ыбызда да яңа коллектив, әлегә ияләшү чоры дип уйлыйм. Кем эшләми, шуның хаталары юк. Безнекеләр хаталарын төзәтер дип уйлыйм. Соңгы уеннарында нәтиҗәләр бар бит инде.

**Илшат Гарифуллин (Кайбыч районы Кошман авылы, «Ак барс»ның күптәнге җанатары):**

– Быелгы «Ак барс» өч тапкыр Гагарин кубогын откан «Ак барс»ка бер дә охшамаган бит әле. Өметләребез зурдан иде. Сезонны зарыгып көттек. Әллә тренер эшләп бетерми, әллә командадагы уенчылар тәҗрибәсе җитми… Көчле состав та тупладык инде югыйсә. Кайбер хоккейчыларның бөтенләй нәтиҗәсез уен күрсәтүләре борчый. Карарга киләбез, йөрибез, ышанабыз да бит… Алга таба болай барса – бик начар. Гаеп кемдә – аттамы, тәртәдәме? Белгән юк…

**Хоккей командасының «ВКонтакте»дагы төркемендәге фикерләр:**

**Рафис:** Хоккейны «Арена»га барып карадым, уенчылар арасында үзара аңлашу күрмәдем. Яшьләр бозда йөгереп йөри, башкалар шайбаны көтеп тора. Төгәл пас та юк. Кая телиләр, шунда сугалар. «СКА» белән очрашу да шундый ук булачак.

**Роман:** «Ак барс»ны икенче периодта гына күрдек. Баш тренерга командадагы вазгыятькә барыбер кебек.

**Антон:** СКА белән уенга чыгып тормасагыз да була.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

## 91 ЯШЬЛЕК ФӘҮЗИЯ ӘБИ:

# «КИТАПСЫЗ ТОРА АЛМЫЙМ»

**Китапны су урынына эчүче ак әбиебез. Чистай районының Исләй авылында гомер итүче 91 яшьлек Фәүзия Закирова турында авылдашлары, яратып, әнә шулай ди.**

– Авылыбызның иң өлкән кешесе мин, кызым. Аллаһы Тәгалә менә шулай озын гомер насыйп киткән. Әти-әни бик яшьли мәрхүм булдылар. Мин аларның да гомерен яшим, күрәсең. 12 яшемдә ятим калдык. Әти белән әни, авырып, өч көн эчендә бер-бер артлы үлеп киттеләр. Абыем һәм сеңлем белән – йортта өч ятим утырып калдык, – дип сүзен башлады ул.

Фәүзия әби әйтүенчә, озын гомеренең сере – хәрәкәттә.

– Мин бит бер дә тик тормадым, бик нык эшләдем. Хәрәкәттә – бәрәкәт. Хәрәкәтләнергә кирәк. Саулыкның бөтен сере шунда. Әллә кайдан эзлисе дә түгел аны. Элек сыер да саудым, бригадир да булдым, халыктан сөт тә җыйдым, читкә барып та эшләп кайттым. Бүген тормышыма шөкер итеп туя алмыйм. Бик канәгать.

Фәүзия әби газета-журналларны әле дә булса күзлексез укый икән. Алай гына да түгел, аның иң яраткан эше – китап уку.

– Авылыбызның ак әбисе ул, – дип сүзгә кушылды китапханәче Зөлфия Фәтхетдинова. – Бик яратабыз үзен. Һәрчак матур итеп ак яулыгын ябынып, елмаеп каршы ала. Авылыбызның иң өлкән кешесе генә түгел, иң күп китап укучысы да ул безнең. «Яхшы китаплар гына бир син миңа», – дип тора ул. Китапханәдә ул укымаган китап бик аз калып бара инде.

Чыннан да, бар булмышы, бар тормышы аклыктан, яхшылыктан торган кешеләр генә ак әби була торгандыр да авылдашларының ихтирамын һәм игътибарын яулый ала торгандыр шул.

– Тугызар китап алып кайтам, – дип китапханәченең сүзен җөпләп алды кызы Фәридә апа. – Сәгать төнге 2дә торсам да, 3тә торсам да, әни китап укый торган була. Кайвакыт, төн белән көнне алыштырып бетерә инде дип, утны өзеп куям. Ул төнне сәгать иртәнге 5кә кадәр ут эзләп чыга. Шуннан соң гына, килешеп, йокыга китә. Укырга бик ярата.

– Әйе шул, бертуктамый китап укыйм мин, – дип канәгать елмаю белән әйтеп куйды Фәүзия әби. – Барлык темаларны да яратам. Шулай да тарихны аеруча үз итәм. Шуларны укыйм да, анализ ясыйм, күп вакыйгаларга башка яктан карый башлыйм.

Балалары төрле җирләрдә сибелешеп яшәсә дә, пенсиягә чыккач, кызы Фәридә апа әнисе янына кайта.

– Әнием үз-үзен карый алса да, янында булыйм дип, пенсиягә чыккач, Калининградтан авылга кайттым, – ди ул. – Аллага шөкер, әлегә кадәр барысын да үзе эшли. Урамга да чыгып әйләнеп керә. Тегүгә дә бик оста. Кирәк икән, күлмәген дә җәһәт кенә төзәтеп куя. Кул белән дә булдыра, машинага тотынырга да аптырап тормый. Менә колагы гына начаррак ишетә башлады. Исән генә булсын, дип телибез. Ул булганда, без – бала әле.

Бүгенгесенә шөкер итеп яшәсә дә, гомер йомгагын сүткәндә сөенече дә, көенече дә шактый булган Фәүзия әбинең. Ире Вагыйзь белән йорт тергезеп, бер чүмеч он белән башка чыгу, авыр эшләрдә эшләү, итәк тутырып бала үстерү, аннан соң шуларның икесен җир куенына иңдерү. Болар берсе дә эзсез узмаган. Кеше күңелендә тирән эз калдырган вакыйгалар, истәлекләр, мизгелләр әледән-әле искә төшеп, күңел кылларын тибрәтә торган була бит. Ятимлек ачысы, колхозга керү, балаларын югалту ачысы – Фәүзия әбинең кабат-кабат кайтып сөйли торган темалары.

– Әнием бик укымышлы кеше иде. Хатын-кызларны җыеп, аларга гыйлем бирә торган иде. Әтием читкә китеп эшләде. Колхозлашу башлангач, кемдә нәрсә бар, шуны уртак казнага җыя башладылар бит. Әнием колхозга шунда ук керде. Ә менә әтием керергә теләмичә карышты. Өйдә бик зур сәгатебез бар иде безнең. Идәннән алып түшәмгә кадәр булган бу сәгатьне талап диярлек өйдән алып чыгып киттеләр. Шул зур сәгать әле дә булса күз алдымда, – ди ул.

Безнең исә күзебез караватбашында төсле бизәкләр чигеп төшерелгән ак сөлгегә төште.

– Әнием истәлеге, дип саклый ул аны. Беркемгә дә тидертми. Гел шушында тота, – дип соравымны да көтмичә ачыклык кертте Фәридә апа. – 12 яшендә әнисеннән калса да, аны искә алмаган көне юк. Тормышы җиңел генә бармаган инде әнинең. Исенә төшкән саен елый-елый сөйли. Ә безнең аны бер дә борчыйсыбыз килми. Саклап-кадерләп кенә яшәтәсебез килә.

Менә шулай балаларының һәм авылдашларының кадер-хөрмәтен тоеп, матур әбиебезгә бәрәкәтле гомер теләдек.

Зөһрә САДЫЙКОВА

**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Тираж – 6697 данә**
**Гомуми тираж – 15337 данә**

**Газетага сертификат бирелде** Заказ 368

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

**www.vatantat.ru**

**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**

**89179270040**

**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР

**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+